DOI: 10.26907/2311-2042-2025-24-1-146-152

# A TREASURE TROVE OF MEMOIRS BY THE OUTSTANDING BOOK CRITIC ABRAR KARIMULLIN (ON THE 100TH ANNIVERSARY OF THE SCHOLAR)

**Gulnira Razifovna Khusainova,**
National Library of the Republic of Tatarstan,
86 Pushkin Str., Kazan, 420015, Russian Federation,
Gulnira2010@yandex.ru.



**Karimullin Abrar Gibadullovich** (1925–2000) was an academician, the first researcher of the Tatar book history, a bibliographer, Doctor of Philology, full member of the Academy of Sciences of Tatarstan, Honored Scientist of the TASSR, winner of the State Prize of the Republic of Tatarstan named after G. Tukay, winner of the Kul Gali International Prize, holder of high titles in various nominations in many countries of the world. He participated in the Great Patriotic War.

Abrar Karimullin graduated from the Faculty of History and Philology of Kazan State University named after V. I. Lenin (1953). In 1953–1964 he was deputy director for research at the Scientific Library of Kazan State University; in 1964–1992 he worked at the G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan.

In 1991–1992, A. Karimullin was a scientific consultant of the National Library of Tatarstan.

He conducted research on the

**Кәримуллин Әбрар Гыйбадулла улы** (1925–2000) – танылган татар галиме, китап белгече-библиограф, филология фәннәре докторы (1978), Татарстан фәннәр Акдемиясенең хакыйкый әгъзасы (1992), ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1987), Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1991), Кол Гали исемендәге Халыкара премия лауреаты (1995).

Бөек Ватан сугышында катнаша. В.И. Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый (1953). 1953-1964 елларда Казан дәүләт университетының Фәнни китапханәсендә фәнни эшләр буенча директор урынбасары. 1964-1992 елларда Г. Ибраһимов исемендәге Татарстан фәннәр Академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшли.

1991-1992 елларда Татарстан Милли китапханәсендә фәнни консультант вазыйфасын башкара.

**Каримуллин Абрар Гибадуллович** (1925–2000) – известный татарский ученый, книговед-библиограф, доктор филологических наук (1978), действительный член Академии наук Татарстана (1992), заслуженный деятель науки ТАССР (1987), лауреат Государственной премии РТ имени Г. Тукая (1991), лауреат Международной премии имени Кул Гали (1995).

Участник Великой Отечественной войны.

Выпускник историко-филологического факультета Казанского государственного университета имени В. И. Ленина (1953). В 1953–1964 гг. был заместителем директора по научной части Научной библиотеки Казанского государственного университета, в 1964–1992 гг. работал в Институте языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова Академии наук Татарстана.

В 1991–1992 г. – научный консультант Национальной библиотеки Татарстана.

Автор исследований по исто-

history of the Tatar people, his major works were devoted to the history of the emergence and development of the Tatar printed book, philology and bibliography.

Татар халкы тарихы буенча тикшеренүләр авторы, төп хезмәтләре татар басма китабының барлыкка килү һәм үсеш тарихына, тел гыйлеме һәм библиографиягә багышланган.

рии татарского народа, основные труды посвящены истории возникновения и развития татарской печатной книги, филологии и библиографии.

**For citation:** Khusainova, G. A treasure trove of memoirs by the outstanding book critic Abrar Karimullin (on the 100th anniversary of the scholar) // Tatarica. 2025. № 1 (24). pp. 146–152. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-146-152

**Сылтама өчен:** Хөсәенова Г.Р. Танылган китап белгече Әбрар Кәримуллинның истәлек-хәзинәсе (галимгә 100 яшь тулу уңаеннан) // Tatarica. 2025. № 1 (24). 146–152 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-146-152

**Для цитирования**: Хусаинова Г.Р. Памяти известного книговеда-библиографа Абрара Каримуллина (к 100-летию со дня рождения ученого) // Tatarica. 2025. № 1 (24). С. 146–152. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-24-1-146-152

The Department of Manuscripts and Rare Books of the National Library of the Republic of Tatarstan has a memorial room with a complete presentation of the Tatar people's history, culture and literature. The "owner" of this room was Abrar Karimullin, an outstanding Tatar academic bibliographer, one of the first researchers of the Tatar book who made significant contributions to all of these areas of our life.

The memorial room is based on a collection of books, handwritten materials, photographs, certificates of honour, orders and medals, transferred from the scientist's personal library. Before starting to study A. Karimullin's room, it is appropriate to briefly outline his life and research work.

Abrar Karimullin was born on May 29, 1925 in the village of Chabya-Churchi in the Sabinsky District of the TASSR. He graduated from high school in 1941. The desire of the young man, who excelled in his studies, was to continue his education and master the profession of a teacher. But the news of the outbreak of the war made him temporarily forget about these dreams. The future scholar was drafted into the army on January 7, 1943, and later went to the front. He participated in the battles on the Kursk Bulge, crossed the steppes of Mongolia, China and the Khingan Mountains. Wounded and shell-shocked three times, he returned to his native village only in 1947 [1].

After the end of the war, A. Karimullin had the opportunity to complete his education and take up scientific research. In 1953, he successfully graduated from the Faculty of the Tatar Language and Literature at Kazan University and got a job at the scientific library of Kazan University. During his time at the library, the young professional established himself as a leader, bibliographer and archaeographer who knew how to organise thorough research. Here, he published articles on the work of Tatar writers, their literary connections and the history of their success. During these years, A. Karimullin prepared numerous bibliographic indexes on the history of Tatar literature, its translations into Russian and the languages of the peoples of the USSR, on linguistics and the history of the TASSR.

In 1964, he was invited to work at the Institute of Language, Literature and History. In 1968, without doing a postgraduate course, he defended his Ph.D. thesis "The emergence of Tatar printing and new sources on Tatar philology: the 17$^{th}$ – the 1$^{st}$ half of the 19 centuries", simultaneously performing the duties of his main occupation. In 1971, the dissertation materials were published in a separate book entitled "At the Origins of the Tatar Book: from the Beginning of the Renaissance to the 1860s" [2]. His interest in the history of the book made Abrar Karimullin write, within a short time, a major scientific work "The Tatar Book of the Early 20$^{th}$ Century", on its basis he defended his doctoral thesis in 1970 and received the degree of Doctor of Philology. In 1983, his monograph "The Tatar Book of Post-Reform Russia" was published [3]. These fundamental works of the scholar are devoted to the study of the history of the Tatar printed word from the moment of its origin to 1917.

Abrar Karimullin wrote many monographs on the history and culture of the Tatar people, on the importance of preserving their native language. Among them are: "We Left a Mark in History" [5], "The Language is the Guardian of the Nation" [6], "Tatars: Our Name and Our Essence" [7].

A. Karimullin was interested in the issue of the similarity between languages. He was one of the first in the history of world science to study the genetic similarity between the Turkic languages and the languages of the Maya, Incas, Aztecs and Aymara Indians. His findings were published in a separate book in 1995 [8].

In 1991, Abrar Karimullin, at the suggestion of Razil Valeev (who held the post of the head of the National Library in those years), got a job as a scientific consultant to the National Library of the Republic of Tatarstan. From that year on, a specially created team of researchers, led by A. Karimullin in the National Library of Tatarstan, was busy compiling a complete consolidated catalogue of Tatar printed books published before 1917. Being a major expert in the field of book studies and bibliography, A. Karimullin not only supervised this work, but also carried out most of it himself: he collected data on the circulation of books, compiled card files for individual publishers, identified the authors of books and people related to the history of the book.

The memorial room of A. Karimullin is of great importance for preserving the cultural heritage of the Tatar people, as well as as a storage place for scientific publications. As for his personal collection, it is based on books, journals, personal handwritten collections of research papers, photographs, archival documents, postcards and booklets. The chronological boundaries of the Foundation cover the period from 1870 to 2005. There are about four thousand books in Tatar, Russian, English, Turkish and Bashkir, devoted to the issues of linguistics, literary studies, history and bibliography.

The image of printed books, belonging to the A. Karimullin Foundation, deserves special attention. They carry an ex-libris in the form of a 10x12 cm paper sticker with a drawing and text *Abrar Karimullin kitabь* (Abrar Karimullin's book). Moreover, according to his will, each book has an image of the Syuyumbike Tower (the Kazan Kremlin) and the inscription "*Qazan. Abrar Karimullin*", as well as the word "*Kazan*" in Arabic script and the address of the scientist (420012 Kazan-12, Ulyanovykh Str., 57/12, 32. Karimullin Abrar Gibadullovich), stamped with a rectangular stamp.

A. Karimullin's collection, along with other scientific works, includes books related to literature and art. The fund can be divided into several groups:

- books by Abrar Karimullin;
- works, aimed at studying the history and linguistic characteristics of particular people;
- dictionaries;
- works by famous Tatar writers;
- periodicals;
- books, written in Turkish, Kazakh, Uzbek and English.

In the rich library of the academician, you can get acquainted with theoretical materials on Tatar literature, works representing different eras. The shelves of the memorial room feature works by Kul Gali, Mukhammedyar, G. Kandaly, K. Nasyri, G. Tukai, G. Ibragimov, G. Iskhaki, H. Taktash, N. Isanbet and G. Bashirov. The collection also includes the works of the famous Tatar scientists M. Zakiev, M. Usmanov, Kh. Minnegulov, F. Garipova and others.

A significant place in A. Karimullin's collection is occupied by the works of Russian scientists such as V. Bartold, V. Klyuchevsky, I. Krachkovsky and books on bibliography, published in different years. The Fund really values the dictionaries of the Tatar-Russian and Russian-Tatar, Arabic-Russian and Tatar-Turkic languages, dictionaries of terminology and encyclopedic dictionaries of the Tatar language.

Over the years, several bio-bibliographic indexes have been published, reflecting the life and research work of Abrar Karimullin [9–11]. These data, which cover an extensive list of literature, indicate that the scholar's scientific work was quite long and versatile.

No matter what field A. Karimullin worked in, he followed the path that he considered right, each of his studies was characterized by a new approach to well-known phenomena, events and facts. Apparently, this explains the popularity of his works with the general public.

Abrar-aga was actively working to find his front-line friends with whom he had been together in the war, and he corresponded with his friends from different regions. These letters are carefully kept in the memorial room of the library. The handwritten memoirs reflect the feelings of soldiers who fought together against the enemy, were happy to return to a peaceful life, who found each other and rejoiced in each other's success.

The great Tatar scholar, unique personality, academician A. Karimullin died on September 18, 2000 at the age of 75. The academician's contemporaries recalled that he worked tirelessly, was a man of restless soul, and strove to improve his knowledge. Despite all the difficulties of research and social work, he remained faithful to the

book, reflecting the history, search and people's way of life. It is this position of the scientist that served as an important factor in his successful study of the history of the Tatar book from its origin to the present day.

Since May 3, 2003, the National Library of the Republic of Tatarstan has been hosting the International Research and Practice Conferences "Karimullin ukulary" ("Karimullin Readings"). The readings include scientific reports on the national book issue and related memoirs of the people who knew the scholar intimately.

In 2017, the conference materials were collected and published by the National Library Publishing House. The collection, consisting of two parts, contains articles by scientists from Lithuania, Belarus, Kazakhstan, Turkey, as well as from Kazan, Moscow, St. Petersburg, Simferopol and Makhachkala, those who participated in these readings in the period from 2003 to 2016 [12].

As we know, Abrar Karimullin was highly respected by his fellow villagers. This is evidenced by the fact that the central library of the Sabinsky District has been named after Abrar Karimullin since 2001. Of the scientist's fellow villagers, his close ties with Talgat Nazmiev are best-known. The letters, written by the journalist and the academician, were published in 2018 in a periodical called "Abrar Karimullin's Letters" [13–14].

Every nation has its enterprising, intelligent sons and daughters that it is proud of. Among them is Abrar Karimullin. During his lifetime, he studied the history of the Tatar book, and made the Tatar nation known to the general public. I would like to believe that his works will retain their significance, and representatives of the younger generation will continue on the glorious path of the scholar.

**References**

1. *Abrar Gibadullovich Karimullin: biobibliograficheskii ukazatel'* (1995) [Abrar Gibadullovich Karimullin: Bio-bibliographic Index]. Sost. R. Kh. Timergalina. 73 p. Ufa-Kazan'. (In Russian)

2. Karimullin, A. G. (1971). *U istokov tatarskoi knigi (ot nachala vozniknoveniya do 60-kh godov XIX veka)* [At the Origins of the Tatar Book (from its beginning to the 1860s)]. 224 p. Kazan', Tatar. kn. izd-stvo. (In Russian)

3. Karimullin, A. G. (1983). *Tatarskaya kniga poreformennoi Rossii* [The Tatar Book of Post-Reform Russia]. 320 p. Kazan', Tatar. kn. izd-vo. (In Russian)

4. Karimullin, A. G. (1974). *Tatarskaya kniga nachala XX veka* [The Tatar Book of the Early Twentieth Century]. 320 p. Kazan', Tatar. kn. izd-vo. (In Russian)

5. Karimullin, A. G. (2000). *Bez tarikhta ehzlebez* [We Left a Mark in History]. 464 p. Kazan', Natsional'naya kniga. (In Tatar)

6. Karimullin, A. G. (1997). *Tel - millətneң sakchysy* [The Language Is the Guardian of the Nation]. 256 p. Kazan', Tatar. knizhn. izd. (In Tatar)

7. Karimullin, A. G. (1991). *Tatarlar: isemebez həm җisemebez* [Tatars: Our Name and Our Essence]. 160 p. Kazan', Tatar. knizhn. izd. (In Tatar)

8. Karimullin, A. G. (1995). *Prototyurki i indeitsy Ameriki. Po sledam odnoi gipotezy* [Proto-Turks and American Indians. Following One Hypothesis]. 65 p. Moscow, Insan. (In Russian)

9. *Abrar Gibadullovich Karimullin: biobibliograficheskii ukazatel'* (1985) [Abrar Gibadullovich Karimullin: Bio-bibliographic Index]. Sost. T. S. Korbangaleeva. 35 p. Kazan', KGU. (In Russian)

10. *Abrar Gibadullovich Karimullin: biobibliograficheskii ukazatel'* (1995) [Abrar Gibadullovich Karimullin: Bio-bibliographic Index]. Sost. R. Kh. Timergalina. 73 p. Kazan'. (In Russian)

11. *Əbrar Gyibadulla uly Kərimullin: biobibliografik kyrsətkech* (2011) [Abrar Gibadullovich Karimullin: Bio-bibliographic Index]. Təz. A. F. Məkhmүtova. 271 p. Kazan. Milli kitap. (In Tatar)

12. *Milli kitap: үtkəne həm bүgengese, kiləchəkkə karash* (2017) [The National Book: Its Past and Present, a Look to the Future]. I-V Kərimullin ukulary – khalykara fənni-gaməli konferentsiyalər materiallary (Kazan, 2003–2016 ellar) 2 kisəktə. I kisək. Təz.: I. G. Һadiev, A. Җ. Zahidullin. 278 p. Kazan, Milli kitap. Milli kitap: үtkəne həm bүgengese, kiləchəkkə karash: I-V Kərimullin ukulary – khalykara fənni-gaməli konferentsiyalər materiallary (Kazan, 2003–2016 ellar) 2 kisəktə. II kisək; təz.: I. G. Һadiev, A. Җ. Zahidullin. 224 p. Kazan, Milli kitap. (In Tatar)

13. Nəҗmiev, T. S. (2018). *Əbrar Kərimullin khatlary* [Abrar Karimullin's Letters]. Bezneң Miras. No. 9, pp. 77–79. (In Tatar)

14. Nəҗmiev, T. S. (2011). *Əbrar Kərimullin khatlary* [Abrar Karimullin's Letters]. Mədəni җomga. No. 38, pp. 14–15.; No. 39, p. 15.; No. 40, p. 15. (In Tatar)

# ТАНЫЛГАН КИТАП БЕЛГЕЧЕ ӘБРАР КӘРИМУЛЛИННЫҢ ИСТӘЛЕК-ХӘЗИНӘСЕ (ГАЛИМГӘ 100 ЯШЬ ТУЛУ УҢАЕННАН)

**Гөлнирә Рәзиф кызы Хөсәенова,**
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе,
Россия, 420015, Казан ш., Пушкин ур., 86 нчы йорт,
Gulnira2010@yandex.ru

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә татар халкының тарихы, мәдәнияте, әдәбияты тулысы белән чагылдырылган мемориаль бүлмә эшләп килә. Әлеге бүлмәнең «хуҗасы» алда санап үтелгән барлык өлкәләргә дә саллы өлеш керткән библиограф, беренчеләрдән булып татар китабын өйрәнүче, күренекеле татар академигы – Әбрар Кәримуллин.

Мемориаль бүлмәнең төп нигезен галимнең шәхси китапханәсеннән тапшырылган китаплар, кулъязма материаллар, фоторәсемнәр, мактау кәгазьләре, орденнар һәм медальләр коллекциясе тәшкил итә. Ә. Кәримуллинның бүлмәсен күзәтүгә керешкәнче, аның кыскача тормыш юлын һәм гыйльми эшчәнлеген бәян итү урынлы булыр.

Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин 1925 елның 29 маенда ТАССР ның Саба районы Чәбия-Чүрчи авылында туа. Урта мәктәпне 1941 елда тәмамлый. Бик яхшы укып килгән егетнең теләге, укуын алга таба дәвам итеп, укытучы һөнәрен үзләштерү була. Тик сугыш башлану хәбәре бу хыялларны вакытлыча онытып торырга мәҗбүр итә. Булачак галим үзе дә 1943 елның 7 гыйнварында армиягә алына, соңрак фронтка китә. Курск дугасындагы сугышларда катнаша, Монголия, Кытай далаларын, Хинган тауларын кичә. Өч тапкыр яраланып, контузияләнгән егет туган авылына 1947 елда гына кайта [1].

Сугыш тәмамлангач, Ә. Кәримуллинга белем алу, фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнү мөмкинлеге ачыла. 1953 елда ул Казан университетының татар теле һәм әдәбияты факультетын уңышлы тәмамлый һәм Казан университетының Фәнни китапханәсенә эшкә урнаша. Китапханәдә эшләү дәверендә яшь белгеч үзен җитәкче, библиограф, археограф, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген төгәл итеп оештыра белүче буларак таныта. Биредә ул татар язучыларының иҗаты, әдәби бәйләнешләр һәм аның тарихын өйрәнүгә нигезләнгән мәкаләләр бастыра. Бу елларда Ә. Кәримуллин татар әдәбияты тарихы, аны рус һәм СССР халыклары телләренә тәрҗемә итүгә, тел гыйлеменә, ТАССР тарихына кагылышлы күпсанлы библиографик күрсәткечләр әзерли.

1964 елда Әбрар Кәримуллин Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институына эшкә чакырыла. 1968 елда аспирантура курсы үтмичә, төп эшеннән аерылмыйча, «Возникновение татарского книгопечатания и новые источники по татарской филологии: XVII–I половина XIX вв. (Татар китап басуының барлыкка килүе һәм татар филологиясе буенча яңа чыганаклар: XVII–XIX гасырның беренче яртысы)» темасына кандидатлык диссертациясе яклый. 1971 елда диссертация материаллары «У истоков татарской книги: от начала возрождения до 60-х годов XIX века (Татар китабының башлангыч чорында: яңарыш башланудан алып XIX гасырның 60 нчы елларына кадәр)» исеме белән аерым китап булып басылып чыга [2].

Яшь галимнең китап тарихы белән кызыксынуы тагын да арта – кыска гына вакыт эчендә ул XX гасыр башы татар китабы тарихы буенча зур фәнни хезмәт яза. Әлеге эш 1970 елда докторлык диссертациясе буларак яклана, ә 1974 елда монография аерым китап булып басылып чыга. 1983 елда аның тагын бер китабы «Татарская книга пореформенной России» (Реформадан соңгы Россиянең татар китабы) дөнья күрә [3]. Шулай итеп, Ә. Кәримуллин татар басма китабы тарихына багышланган өч күләмле фәнни эшнең авторы булып тора: «У истоков татарской книги» (Татар китабы чыганакларында) [2]; «Татарская книга начала XX века» (XX гасыр башы татар китабы) [4]; «Татарская книга пореформенной России» (Реформадан соңгы Россиянең татар китабы) [3]. Бу өч зур фундаменталь хезмәтнең барысы да татар басма сүзенең барлыкка килү чорыннан алып 1917 елга кадәрге тарихын өйрәнүгә багышланган.

Әбрар Кәримуллинның татар халкының тарихы һәм мәдәнияте, ана телен саклауның әһәмиятен чагылдырган монографияләре

бихисап. «Без тарихта эзлебез»[5], Тел – милләтнең сакчысы»[6], «Татарлар: исемебез һәм җисемебез»[7] дип аталган китаплары да әнә шундыйлардан.

Ә. Кәримуллинны телләр арасындагы охшашлык мәсьәләсе кызыксындыра. Ул, дөньякүләм фән тарихында беренчеләрдән булып, төрки телләр һәм майя, инк, ацтек, аймара индеецлары арасында булган генетик охшашлыкны өйрәнә. Әлеге эзләнүләр 1995 елда аерым китап булып басылып чыга [8].

1991 елда Әбрар Кәримуллин, Рәзил Вәлиев (ул елларда Милли китапханә җитәкчесе вазифасын башкарган) тәкъдиме белән, Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең фәнни консультанты булып эшкә урнаша. Шул елдан Татарстан Милли китапханәсендә фәнни хезмәткәрләрдән махсус оешкан төркем Ә. Кәримуллин җитәкчелегендә 1917 елга кадәр чыккан татар басма китапларының тулы җыелма каталогын төзү белән шөгыльләнә. Татар китабы тарихын өйрәнүдә, гомумән, китап һәм библиография белемнәре өлкәсендә зур белгеч буларак, Ә. Кәримуллин бу эш белән җитәкчелек итеп кенә калмый, ә аның зур өлешен үзе башкара: китапларның тиражларын ачыклаган мәгълүматларны туплый, аерым нәшриятлар һәм матбагалар буенча картотекалар төзи, китап авторларын һәм китап тарихына кагылышлы шәхесләрне ачыклый.

Ә. Кәримуллинның мемориаль бүлмәсе татар халкының мәдәни мирасын чагылдыру, шулай ук фәнни басмаларны саклау урыны буларак, зур әһәмияткә ия. Шәхси тупланмага килгәндә, аның нигезен китаплар, журналлар, галимнең шәхси кулъязма җыентыклары, фотосурәтләр, архив документлары, открыткалар, буклетлар тәшкил итә. Фондның хронологик чикләре 1870 елдан алып 2005 елга кадәр чорны үз эченә ала. Биредә татар, рус, инглиз, төрек, башкорт телләрендә тел белеме, әдәбият белеме, тарих, библиография мәсьәләләренә багышланган 4 меңгә якын китап тупланган.

Ә. Кәримуллин фондына караган басма китапларның сурәтләнеше аеруча игътибарга лаек. Биредә Abrar Karimullin kitabь (Әбрар Кәримуллин китабы) дип аталган рәсемле һәм текстлы, 10х12 см зурлыкта булган кәгазь наклейка рәвешендәге экслибрис тәкъдим ителә. Өстәвенә, академик васыяте буенча, һәр китапка Сөембикә манарасы (Казан кремле) сурәте һәм «Qazan. Abrar Karimullin», шулай ук гарәп шрифтында «Казан» сүзе һәм галимнең адресы (420012 Казань-12, ул. Ульяновых, 57/12, кв. 32. Каримуллин Абрар Гибадуллович) язылган турыпочмаклы штемпель сугылган.

Ә. Кәримуллин тупланмасы, фәнни хезмәтләр белән беррәттән, әдәбият һәм сәнгать өлкәсенә кагылышлы китапларны да колачлый. Шартлыча, фондны берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

– Әбрар Кәримуллин авторлыгындагы китаплар;

– билгеле бер халыкның тарихын һәм тел үзенчәлекләрен өйрәүгә юнәлдерелгән хезмәтләр;

– сүзлекләр;

– танылган татар әдипләренең әсәрләре;

– периодик басмалар;

– төрек, казах, үзбәк, инглиз телендә язылган китаплар.

Академикның бай китапханәсендә татар әдәбиятына караган теоретик материаллар, төрле чорларга караган әсәрләр белән танышырга мөмкин. Мемориаль бүлмә киштәләрендә Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Г. Кандалый, К. Насыйри, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Һ. Такташ, Н. Исәнбәт, Г. Бәширов әсәрләре урын алган. Шулай ук тупланмада М. Зәкиев, М. Усманов, Х. Миннегулов, Ф. Гарипова һ.б. танылган татар галимнәренең хезмәтләре дә бихисап.

Ә. Кәримуллин тупланмасында В. Бартольд, В. Ключевский, И. Крачковский кебек галимнәребезнең хезмәтләре һәм библиография фәненә кагылышлы төрле елларда нәшер ителгән китаплар шактый зур урын алып тора. Татар-рус һәм рус-татар, гарәп-рус, рус-төрки телләрендәге сүзлекләр, терминнар сүзлекләре һәм татар теленең энциклопедик сүзлекләре сакланып килүе дә фондның кыйммәтен арттыра төшә.

Төрле елларда Әбрар Кәримуллинның тормыш юлын һәм фәнни эшчәнлеген чагылдырган берничә биобиблиографик күрсәткеч басылды [9–11]. Күпсанлы әдәбият исемлеген колачлаган әлеге күрсәткечләр галимнең фәнни хезмәт юлы шактый озын һәм киңкырлы булуы хакында сөйли.

Ә. Кәримуллин нинди генә өлкәдә эшләмәсен, ул үзе дөрес дип тапкан юл белән бара, аның һәр тикшеренүе мәгълүм күренешләргә, вакыйгаларга, фактларга яңача якын килү белән аерылып тора. Күрәсең,

хезмәтләренең киң аудиториядә популяр булуы да нәкъ менә шуның белән аңлатыла.

Әбрар Кәримуллинның халыкта дөрес милли үзаң, гыйлемгә омтылыш тәрбияләү белән генә чикләнеп калмыйча, Бөек Ватан сугышы елларында домшманнарга каршы көрәштә актив катнашуы да зур игътибарга лаек. Мәгълүм булганча, сугыштан соң галим фронтташ дусларын эзләүдә актив эш алып бара, төрле төбәкләрдә яшәүче дуслары белән хат алыша. Әлеге хатлар мемориаль бүлмәдә кадерләп сакланалар. Бу кульязма истәлекләрдә дошманга каршы бергә сугышкан солдатларның тыныч тормышка кайткач бер-берсен табу, уңышлары өчен шатлану хисләре күзгә ташлана.

Татар халкының бөек галиме, кабатланмас шәхес, академик Ә. Кәримуллин 2000 елның 18 сентябрендә 75 яшендә вафат булды. Академикның замандашлары аның армый-талмый эшләвен, тынгысыз җанлы кеше булуын, алган белемнәрен тагын да күтәрергә, камилләштерергә омтылуын искә төшерәләр. Фәнни һәм иҗтимагый эшчәнлегендәге барлык кыенлыкларга карамастан, ул кешелекнең тарихын, эзләнүләрен, көнкүрешен чагылдырган китапка тугры кала. Галимнең нәкъ менә шундый карашы татар китабының барлыкка килүеннән алып бүгенге көнгә кадәр тарихын уңышлы өйрәнүдә мөһим фактор булып хезмәт итә.

2003 елдан Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «Кәримуллин укулары» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе үткәрелеп килә. Укуларда китап тарихы мәсьәләләрен өйрәнүче төрле илләрдән, шәһәрләрдән килгән белгечләр һәм галимнәр тирән эчтәлекле фәнни чыгышлар ясый, галимне якыннан белгән шәхесләр аның турындагы истәлекләре белән уртаклаша. 2017 елда 2003-2016 елларда үткән конференцияләрнең материаллары бергә тупланылып, Милли китапханә редакциясендә нәшер ителде. Ике кисәктән торган җыентыкта әлеге укуларда катнашкан Литва, Белоруссия, Казахстан, Төркия, шулай ук Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Симферополь һәм Махачкала шәһәрләре галимнәренең мәкаләләре урын алды [12].

Мәгълүм булганча, Әбрар Кәримуллинга якташларының хөрмәте чиксез зур. Саба районы Үзәк китапханәсе 2001 елдан Әбрар Кәримуллин исемен йөртә. Галимнең тыгыз элемтәдә булган районДашы журналист Тәлгать Нәҗмиев белән язышкан хатлары 2018 елда вакытлы матбугатта дөнья күрде [13–14].

Һәр халыкның горурланырлык булдыклы, зыялы ул-кызлары була. Әбрар ага Кәримуллин да шундыйлардан. Татар милләтен киң җәмәгатьчелеккә таныткан курку белмәс, тырыш, гыйлемле шәхес ул. Аның хезмәтләре замана шаукымы астында әһәмиятләрен югалтмас, ә галимнең изге юлын яшь буын вәкилләре дәвам итәр дип ышанып каласы килә.

**Әдәбият**


1. Абрар Гибадуллович Каримуллин: биобиблиографический указатель / сост. Р.Х. Тимергалина. Уфа-Казань, 1995. 73 с.
2. *Каримуллин А. Г.* У истоков татарской книги (от начала возникновения до 60-х годов XIX века). Казань: Татар. кн. изд-ство, 1971. 224 с.
3. *Каримуллин А. Г.* Татарская книга пореформенной России. Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. 320 с.
4. *Каримуллин А. Г.* Татарская книга начала XX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. 320 с.
5. *Кәримуллин Ә. Г.* Без тарихта эзлебез. Казан: Милли китап, 2000. 464 б.
6. *Кәримуллин Ә. Г.* Тел – милләтнең сакчысы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 256 б.
7. *Кәримуллин Ә. Г.* Татарлар: исемебез һәм җисемебез. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 160 б.
8. *Каримуллин А. Г.* Прототюрки и индейцы Америки. По следам одной гипотезы. Москва: Инсан, 1995. 65 с.
9. Абрар Гибадуллович Каримуллин : биобиблиографический указатель / сост. Т.С. Корбангалеева. Казань: КГУ, 1985. 35 с.
10. Абрар Гибадуллович Каримуллин : биобиблиографический указатель / сост. Р.Х. Тимергалина. Казань: 1995. 73 с.
11. Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин: биобиблиографик күрсәткеч / төз. А.Ф. Мәхмүтова. Казан. Милли китап, 2011. 271 б.
12. Милли китап: үткәне һәм бүгенгесе, киләчәккә караш: I-V Кәримуллин укулары – халыкара фәнни-гамәли конференцияләр материаллары (Казан, 2003-2016 еллар) 2 кисәктә. I кисәк / төз.: И.Г. Һадиев, А.Җ. Заһидуллин. Казан: Милли китап, 2017. 278 б.; Милли китап: үткәне һәм бүгенгесе, киләчәккә караш: I-V Кәримуллин укулары – халыкара фәнни-гамәли конференцияләр материаллары (Казан, 2003–2016 еллар) 2 кисәктә. II кисәк / төз.: И.Г. Һадиев, А.Җ. Заһидуллин. Казан: Милли китап, 2017. 224 б.
13. *Нәҗмиев Т .С.* Әбрар Кәримуллин хатлары // Безнең Мирас. 2018. №9. Б. 77–79.
14. *Нәҗмиев Т. С.* Әбрар Кәримуллин хатлары // Мәдәни җомга. 2011. № 38. Б. 14–15.; №39. Б. 15.; №40. Б. 15.